ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.01.2024 г. Заинск № 49

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 24 сентябрендәге 582 номерлы «Мәгълүмати элмә такта урнаштыру, элмә такта урнаштыру дизайн-проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" карарына ярашлы рәвештә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 24 сентябрендәге 582 номерлы «Мәгълүмати элмә такта урнаштыру, элмә такта урнаштыру дизайн-проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «формалаштырылган сорауны формат-логик тикшерү, мөрәҗәгать итүче тарафыннан сорауның электрон формасындагы һәр кырын тутыру процессында орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә башкарыла. Бердәм портал тарафыннан дөрес тутырылмаган электрон сорау формасы кыры ачыкланганда гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында мәгълүмати хәбәр аша турыдан туры сорауның электрон формасында хәбәр ителә».

2. Әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең Икътисади үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшкуарлыкка ярдәм итү буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет Җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

О.В. Усик
7-14-14